**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

«22» 02 2022 ел Яр Чаллы № 484

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлегендә урнашкан 16:39:103501:19 кадастр номерлы җир кишәрлегенең территорияне планлаштыру проектын һәм межалау проектын эшли башлау турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5 бүлеге нигезендә, Кече Шилнә авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрен исәпкә алып, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы беренче өлеше 20 пункты, район Уставы нигезендә

## КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлегендә урнашкан 16:39:103501:19 кадастр номерлы җир кишәрлегенең территорияне планлаштыру проектын һәм межалау проектын эшли башларга.
2. Проектлаштыруны территориаль планлаштыру документларына, җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә таянып, техник регламентлар таләпләре нигезендә алып барырга.
3. Әлеге карарны районның рәсми сайтында урнаштырырга.
4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе А. Р. Хәбибуллин